ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» ноября 2025 ел № 301

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнар таләпләренә туры китерү максатларында, шулай ук штат үзгәрешләренә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 20 мартында кабул ителгән «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарны өлешчә каплау максатларында ташучыларга субсидияләр бирү комиссиясе составын раслау турында»гы 70 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 мартында кабул ителгән «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан шәһәр тибындагы маршрутлар буенча автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән пассажирлар һәм багажны даими ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларга һәм (яки) индивидуаль эшкуарларга, яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация үтүне раслаучы яки соңгы алты ай эчендә әлеге авыруны кичерү фактын раслаучы шәхси QR-кодларның пассажирларда булуын, яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинациягә медицина каршылыклары булуын раслаучы гамәлдәге шәхси QR-кодларны тикшерүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы 56 номерлы карары.

2. Бу карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Бу карарның үтәлешен контрольгә алуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Шәмсетдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **И.Х. Салихов**